РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
***Старобарышевского сельского поселения***
Камско-Устьинского
муниципального района

422835, с. Старое Барышево, ул.Центральная, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН/КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Кама Тамагы
муниципаль районы
***Иске Барыш***
***авыл җирлеге***
**Башкарма комитеты**

422835, Иске Барыш авылы, Үзәк урамы, 15
тел.(884377)30-3-18, ИНН / КПП 1622004570 / 162201001 ОКПО 93064659 ОГРН 1061672003436

КАРАР

«20» ноябрь 2020 ел № 14

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенең Кыртапа авылында 2021 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Кыртапа авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Кыртапа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 1 этабын 2020 елнын 02 нче декабренэ 13.00 сэгатькэ билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Кыртапа торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенынын 2 этабын 2020 елнын 03 нче декабренэ 10.00 сэгатькэ билгеләргә

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндэге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлегенә кергән Кыртапа торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (Иске Барыш авыл җирлеге территориясендә яшәмәүче һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2021 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле

әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1) Кыртапа торак пунктында Яшьләр урамы буенча вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эш өчен түләү);
2) Кыртапа торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу);
3) Кыртапа торак пунктында юлларны кардан чистарту, грейдерлау (ягулык-майлау материаллары, фронталь төягеч һәм бульдозер отвалы трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
4) Кыртапа торак пунктында җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, КРН-2,1 Б ротацион чапкычлы трактор өчен запас частьләр сатып алу , килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
5) Кыртапа торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген бүлү тәртибе:

- икенче этапта беренче этапта катнаша алмаган кешеләр катнаша.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Иске Барыш авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Р.Җиһаншин**